**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26 мая 2022 г. № 123

**Әтнә муниципаль район Советының «Әтнә муниципаль районының 2022 елга һәм 2023, 2024 елларның планлы чорына бюджеты турында»гы 2021 елның 15 декабрендәге № 90 карарына үзгәрешләр кертү турында**

Әтнә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе Гыймадиев Ф.И. докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Әтнә муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1). 1, 3, 4 һәм 10 статьяларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 нче Статья.

1. 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

а) Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керем күләме 486062,4 мең сум күләмендә;

б) Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 493551 мең сум;

в) Әтнә муниципаль районы бюджеты дефициты 7488,6 мең сум.

2. 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

3 нче Статья

Әтнә муниципаль районы бюджетында 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджетының фаразланган керем күләмен әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә исәпкә алырга.

4 нче Статья

1. Әтнә районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен 2022 елга бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләре бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре) буенча әлеге карарнын 3 нче кушымтасы нигезендә бүлүне үзгәртергә.

2. 2022 елга Әтнә муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә үзгәртергә.

10 нчы Статья

Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны Әтнә муниципаль районы бюджетында 2022 елда, 8 нче кушымта нигезендә бүлеп, үзгәртергә.

2) Әтнә район башкарма комитетының «Өстәмә акча бүлеп бирү турында»гы карарын расларга:

№ 38, 20.01.2022 ел; № 45, 28.01.2022 ел; № 84, 10.03.2022 ел.;

№ 99, 25.03.2022 ел; № 136, 25.04.2022 ел; № 140, 26.04.2022 ел.

3) Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм www.pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Әтнә муниципаль районы башлыгы-
Әтнә район Советы Рәисе Г.Г.Хәкимов